РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
АЛЬМЕТЬЕВСКИЙ
ГОРОДСКОЙ СОВЕТ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ӘЛМӘТ
ШӘҺӘРЕ СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

«11» март 2021 г. г. Альметьевск № 26

Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Әлмәт шәһәр Советының 2018 елның 31 маендагы 120 номерлы «Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Әлмәт шәһәре Башкарма комитеты турында нигезләмә хакында»гы карарына үзгәрешләр кертү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законга үзгәрешләр кертелүгә бәйле рәвештә, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә

Әлмәт шәһәр Советы КАРАР БИРДЕ:

1. Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Әлмәт шәһәр Советының 2018 елның 31 маендагы 120 номерлы «Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Әлмәт шәһәре Башкарма комитеты турында нигезләмә хакында»гы карарына (Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Әлмәт шәһәр Советының 2019 елның 16 декабрендәге 182 номерлы карары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1 нче кушымтаның «шәһәр Башкарма комитеты вәкаләтләре» 2 бүлегендә түбәндәге кararга:

1.1. 2.2 пунктта:

1.1.1. 3 пунктчаның 12 абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«- федераль закон нигезендә комплекслы кадастр эшләрен башкаруны оештыра һәм территориянең карта-планын раслый;»;

1.1.2. 3 пунктчасына түбәндәге эчтәлекле 13 абзац өстәргә:

«-җирлек территориясендә элек исәпкә алынган күчемсез милек объектларының хокук ияләрен ачыклау буенча чаралар күрә һәм үткәрә, күчемсез мелкәтнең Бердәм дәүләт реестрына кертү өчен күчемсез мөлкәт объектларының хокукка ия булучылары турында белешмәләр җибәрә.»;

1.1.3. 10 пунктчасына түбәндәге эчтәлекле 26, 27 абзацлар өстәргә:

«- участок уполномоченные вазыйфасын биләүче хезмәткәргә һәм аның гаилә әгъзаларына хезмәткәр әлеге вазыйфаны биләгән вакытка торак урыны бирә;

- исерек, наркотик яисә башка токсик халәттәге затларга ярдәм күрсәтү

чараларын күрә;

1.1.4 10 пунктчаның 26 абзацын 28 абзац дип санарга .

2. Район башкарма комитетының Хокук идарәсенә (Ханнанова Ә Б.) әлеге карарны «Альметьевский вестник» газетасында бастырып чыгарырга, «Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталы»нда (PRAVO.TARSTAN.RU) һәм Әлмәт муниципаль районы сайты «Интернет»мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә урнаштырырга.

3. Әлеге карар, әлеге карарның 4 пунктында күрсәтелгән нигезләмәләрдән тыш, рәсми басылып чыкканнан соң үз көченә керә.

4. «Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2020 елның 22 декабрендәге 445-ФЗ номерлы Федераль законның 1 нче кушымтасы 2 бүлеге 2.2 пункты 3 пунктчасы 12 нче абзацында каралган хокук мөнәсәбәтләренә карата 2021 елның 23 мартыннан, «Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2020 елның 30 декабрендәге 518-ФЗ номерлы Федераль законның 1 нче кушымтасы 2 бүлеге 2.2 пункты 3 пунктычасы 13 абзацында каралган каралган хокук мөнәсәбәтләренә карата 2021 елның 29 июненнән үз көченә керә.

5. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны шәһәр Советының социаль мәсьәләләр буенча даими комиссиясенә (Шәйхетдинова Ф.А.) йөкләргә.

Шәһәр Башлыгы Т.Д. Нагуманов